КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1255

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Инвалидларны эшкә урнаштыру, аларның һөнәри адаптацияләвен һәм тотрыклы эш белән тәэмин ителүен булдыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карар белән расланган Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен куллану буенча аңлатулар Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 декабрь, 1255 нче
карары белән расланды

# Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе

1. Бу Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

Субсидия бирү максаты – эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплау.

2. Субсидияләр Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә бюджет акчасын алучы буларак тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) тарафыннан бирелә.

3. Бу Тәртипне тормышка ашыру өчен түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

остаз – эш бирүченең локаль норматив акты белән билгеләнгән, инвалидның һөнәри күнекмәләрне үзләштерүе һәм аларны гамәли эшчәнлектә нәтиҗәле куллануы өчен җаваплы хезмәткәр;

инвалид – инвалидны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза биргән һәм даими эш урынына эшкә урнашу өчен бу Тәртипнең 7 һәм 10 нчы пунктлары нигезендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге белән эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә

урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә төзегән эш бирүчегә җибәрелгән I яки II төркем инвалиды.

4. Эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә (алга таба – шартнамә) төзү хокукына шартнамә төзү өчен гариза бирергә планлаштырыла торган ай алдыннан килә торган айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килгән оешмалар (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, хуҗалык ширкәтләреннән һәм устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында булган җәмгыятьләрдән, шулай ук устав (җыелма) капиталларында мондый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмаларыннан тыш), индивидуаль эшмәкәрләр, крестьян (фермер) хуҗалыклары (алга таба – эш бирүче) ия:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

юридик затлар үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмаган, аларга карата банкротлык процедурасы башланмаган, аларның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаган, индивидуаль эшмәкәрләр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән Россия юридик заты булмаган;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмаган;

билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган.

5. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$SN = K \times N \times M,$$

монда:

SN – эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия күләме, сум;

K – бер айга остазның хезмәтенә түләү чыгымнары күләме, әмма Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән, бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган хезмәт өчен түләүнең минималь күләменнән артмаган күләме;

N – остазлар саны;

M – субсидия бирү вакыты.

6. Субсидия остаз, инвалид, эш хакын саклап һәм эш хакын сакламыйча, ялларда, ел саен түләнә торган ялларда булган, эшне туктатып торган, дәүләт һәм иҗтимагый бурычларны үтәүгә җәлеп иткән (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 114, 128 статьялары, 142 статьясының икенче өлеше, 170, 173, $173^1$, 174 статьялары), остаз, инвалид вакытлыча эшкә сәләтле булмаган чорларда бирелми.

7. Субсидия эш бирүчегә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм эш бирүче арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелгән шартнамә нигезендә эш бирүченең локаль норматив акты белән инвалид өчен остаз билгеләнгән көннән алты ай эчендә бирелә.

Шартнамәдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия күчерү тәртибе, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе, субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсенә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары, субсидия алучы тарафыннан субсидияне кире кайтару очраклары, тәртибе, вакытлары, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру, субсидия алучының халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы, субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәү турындагы нигезләмәләр, шартнамә шартларын бозган өчен җаваплылык күздә тотыла.

8. Шартнамә төзү өчен эш бирүче, агымдагы елның 1 октябреннән дә соңга калмыйча, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада бирелгән форма буенча шартнамә төзү өчен гариза (алга таба – гариза) тапшыра. Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

бу Тәртипнең 5 нче пункты нигезендә башкарылган субсидия күләменең исәп-хисабы;

эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасын куйган, мөһер (мөһере булганда) белән расланган субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында белешмә кәгазе (ирекле формада);

эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасын куйган, эш бирүченең бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган белешмә кәгазе;

эш бирүченең җитәкчесе, индивидуаль эшмәкәр тарафыннан имза куелган, эш бирүченең үзгәртеп оештыру, бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процедурасы башланмавын, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән юридик затларга карата күздә тотылган тәртиптә туктатылмавын, үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавын раслый торган белешмә кәгазе;

инвалид өчен остаз билгеләү турында боерык;

инвалидны эшкә алу турында боерык.

Эш бирүче үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен, яисә физик затны индивидуаль эшмәкәр буларак дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен, яисә Юридик затларның (Индивидуаль эшмәкәрләрнең) бердәм дәүләт реестры язмасы бите күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турында таныклык күчермәсен;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә гариза белән мөрәҗәгать иткәнгә кадәр өч айдан иртәрәк булмаган вакытта бирелгән Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Индивидуаль эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә) күчермәсен;

салым органының Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау турындагы белешмә кәгазен.

Эш бирүче бу пунктның тугызынчы – уникенче абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

9. Гариза халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә кергән көнне, керү көнен һәм вакытын күрсәтеп һәм гаризага теркәүнең тәртип номерын биреп, гаризаларны теркәү журналында (алга таба – теркәү журналы) теркәлә, аның битләре нумерланган, шнурланган һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең мөһере белән расланган була. Гариза почта аша кергәндә, ул кергән көнне халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә почта аша җибәрелгән хатның килү датасын һәм вакытын күрсәтеп теркәлә.

Эш бирүче шәхси мөрәҗәгать иткәндә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны теркәгән көндә аңа гаризаны һәм аңа теркәлгән докуменларны кабул итү көне, бирелгән теркәү номеры турында хәбәрнамә бирә; гариза почта аша кергәндә эш бирүчегә элемтә оешмасы аша язмача хәбәрнамә җибәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге шартнамә төзү турында яки шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итү максатларында гаризаның, аңа теркәлгән документларның гариза кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәвен гариза бирү чираты тәртибендә карап тикшерә.

Эш бирүче бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килгән һәм бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документлар исемлеге нигезендә документлар биргән, тапшырылган документларда дөрес мәгълүматлар булган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны карап тикшерү

вакыты тәмамланган көннән соң килә торган эш көне эчендә Министрлыкның кушуы буенча шартнамә төзү турында карар кабул итә һәм элегрәк теркәлгән гаризалар буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары суммасы бетмәү шарты белән эш бирүчегә, шартнамә проектын ике нөсхәдә теркәп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәрнамә җибәрә.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм эш бирүчегә гаризаны карап тикшерү вакыты тәмамланган көннән килә торган эш көне эчендә түбәндәге очракларда, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәрнамә җибәрә:

эш бирүче бу Тәртипнең 4 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәгәндә;

ул тапшырган документлар бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәгәндә;

бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмаганда (тулы күләмдә тапшырмаганда);

бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән һәм тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар ачыкланганда;

эш бирүче гариза биргән көнгә тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары беткәндә.

10. Эш бирүче халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан җибәрелгән шартнамә алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә ике нөсхәдә шартнамә төзи һәм аны халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бирә.

Эш бирүчедән имза куелган шартнамә алынган көннән килгән бер эш көне эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәге шартнамәгә имза куя һәм шартнамәнең яклар тарафыннан имзаланган бер нөсхәсен эш бирүчегә җибәрә.

Әгәр дә бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт эчендә эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә эш бирүченең имзасы куелган шартнамә тапшырылмаса, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге бу пунктның беренче абзацында күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң ике эш көне эчендә шартнамә төзү турындагы карарны гамәлдән чыгара һәм эш бирүчегә, баш тарту сәбәбен күрсәтеп, әлеге карарны гамәлдән чыгару турында хәбәрнамә җибәрә.

11. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан эш бирүчегә карата бу Тәртипнең 9 нче пунктындагы җиденче – тугызынчы абзацлары нигезендә шартнамә төзүдән баш тарту турында карар кабул ителгән әлеге эш бирүче бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы беренче абзац белән билгеләнгән вакыт эчендә, бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы икенче – җиденче абзацларында күрсәтелгән документлар исемлегеннән җитеп бетмәгән документларны теркәп, яңадан гариза тапшырырга хокуклы.

12. Субсидияне күчерү өчен шартнамә төзегән эш бирүче, остазга эш хакын түләгәннән соң яки остазның кредит оешмаларындагы шәхси счетына эш хакы суммасын күчергәннән соң, эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә ай саен халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә субсидия күчерү турында гариза (ирекле рәвештә) һәм түбәндәге документларның күчермәләрен кертә:

түләү ведомосте (остазга түләнгән эш хакы суммасы турында) яки үткән ай өчен остазның кредит оешмаларындагы шәхси счетына сумма күчерү турындагы

түләү исемлегенең расланган күчермәсен;

үткән ай өчен хезмәт өчен түләү фондына шартнамә нигезендә исәпләнгән иминият кертемнәре суммасын бюджеттан тыш дәүләт фондларына күчерү турында түләү йөкләмәсен;

үткән ай өчен остазның эш вакытын исәпкә алу табелен;

үткән ай өчен инвалидның эш вакытын исәпкә алу табелен.

Инвалид өчен остаз билгеләү турындагы боерык, инвалидны эшкә алу турындагы боерык, башка остазны яки башка инвалидны эшкә алган очракта, өстәмә рәвештә кертелә.

Бу пунктта күрсәтелгән документларның күчермәләре эш бирүченең җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан таныклана һәм оешманың мөһере белән (мөһер булганда) раслана.

13. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге эш бирүченең субсидия күчерү турындагы гаризасы һәм бу Тәртипнең 12 нче пунктында күрсәтелгән документлар кергән көнне аны бу Тәртипнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән теркәү журналында терки.

14. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге субсидия күчерү турында гариза һәм бу Тәртипнең 12 нче пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә эш бирүче янына бара, остазның хезмәте өчен түләү буенча эш бирүченең чыгымнарын, инвалидның эшләү фактын, эш бирүчедә булган документлар нигезендә остазның эшләү фактын раслый торган финанс документларын чагыштыра һәм субсидия күчерү турында яки аны күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

15. Субсидия күчерүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 12 нче пунктында каралган документлар тапшырылмау (тулы булмаган күләмдә тапшырылу);

эш бирүче тарафыннан тапшырылган гаризадагы һәм бу Тәртипнең 12 нче пунктында күрсәтелгән документлардагы мәгълүмат дөрес булмау.

16. Эш бирүчегә субсидия күчерүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге карарны кабул иткән көннән ике эш көне эчендә эш бирүчегә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, кабул ителгән карар турында язмача хәбәр итә.

17. Субсидия халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан ай саен, бу Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә эш бирүче тарафыннан тапшырыла торган күчерү турындагы гаризаны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча субсидия күчерү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә, эш бирүченең Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап счетына күчерелә.

18. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе – эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан хезмәт өчен түләүнең бер өлешен каплауга субсидия бирелә торган инвалидлар өчен остазларның факттагы саны эш бирүченең шартнамә төзүгә гаризасында күрсәтелгән остазлар санына туры килү.

19. Субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турындагы хисапны эш бирүче ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 15 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча халыкны эш белән

тәэмин итү үзәгенә кертә.

20. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджетының чыгымнарны каплау чыганагы булып субсидия торган һәм башкарылган чыгымнары турында, субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында Министрлыкка хисап кертә.

21. Министрлыкка кертелә торган хисапларның дөреслеге өчен җаваплылык халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә йөкләнә.

22. Субсидияләр эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбен алган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш:

эш бирүче тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган, аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, тулы күләмдә;

шартнамәдә каралган субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешмәгән өчен субсидия суммасыннан бер процент күләмендә;

субсидиядән максатчан файдаланылмау ачыкланган очракта, максатчан билгеләнештә файдаланылмаган субсидия күләмендә.

23. Эш бирүче тарафыннан бу Тәртипнең 22 нче пунктында күрсәтелгән иректе рәвештә кире кайтару вакыты бозылган очракта, халыкны эш белән тәэмин итү үзәге әлеге вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә законнар белән билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны мәҗбүри түләтерү буенча чара күрә.

Шул ук вакытта эш бирүче, бу Тәртипнең 22 нче пунктында каралган таләпне алганнан соң киләсе көннән башлап, аны үз вакытында түләмәгән һәр көн өчен, аны кире кайтару көнен дә кертеп, кире кайтарылырга тиешле субсидия суммасыннан 0,03 проценты күләмендә пеня түли.

24. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең эш бирүчеләргә субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары эш бирүчеләр тарафыннан субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

25. Эш бирүчеләр бу Тәртипнең 8, 12, 19 нчы пунктларында күрсәтелгән һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә кертелгән документларның дөреслеге өчен законнар нигезендә җавап бирә.

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
1 нче кушымта

Форма

______________________________
(халыкны эш белән тәэмин итү
______________________ директорына
үзәге исеме )
______________________________
(директорның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә төзү өчен гариза

____________________________________________________________________________
(эш бирүченең исеме, адресы)

инвалидны эш белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәткәндә озатып йөрүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (гаризалар) биргән һәм Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы нигезендә ___________________ ______________________________________________________ һөнәре (белгечлеге) буенча эшкә урнаштырылган I яки II төркем инвалид (инвалидлар) өчен _______ остаз (остазлар) билгеләде һәм аларның хезмәте өчен түләүгә чыгымнар тотты.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» _____ел, ____________, ___ нчы(нче) карары белән расланган Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү турында шартнамә төзүегезне сорыйбыз.

Остазның (остазларның) хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен ____________________ (____________________________________________________________) сум
(суммасы саннар белән) (суммасы сүз белән)
күләмендә акча кирәк булачак.

Шул ук вакытта түбәндәге документлар тапшырыла:
1. ________________________________________________________________________________
2. ________________________________________________________________________________
3. ________________________________________________________________________________
4.________________________________________________________________________________
Барысы ______ биттә.

Өстәмә итеп түбәндәге мәгълүмат тапшырыла:
1. ИНН: __________________________________________
2. Җитәкченең (индивидуаль эшмәкәрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда): ___________________________________________________________________
3. Элемтәгә керү өчен затның (вазыйфасын күрсәтеп) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда): ___________________________________________________________________
4. Юридик адресы:
_______________________________________________________________________________________
5. Факттагы адресы:
_______________________________________________________________________________________
6. Элемтәгә керү өчен телефоны (эш һәм мобиль):
_______________________________________________________________________________________
7. Түләү реквизитлары ___________________________________________________________________:
(юридик затның тулы исеме)
_______________________________________________________________________________________
(кредит оешмасының исеме, БИК, исәп-хисап счеты)

_____________________________ _____________________________________________________
(җитәкче вазыйфасы) (җитәкченең, индивидуаль эшмәкәрнең имзасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.[1]

Баш бухгалтер __________________ __________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20__ел, «___» _______________

__________________
[1]Мөһер булганда.

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Форма

Эш бирүчегә Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениесе юлламасы буенча эшкә урнаштырылган инвалид өчен остазның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү нәтиҗәсе әһәмиятенә ирешү турында хисап

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Күрсәткечнең план буенча мәгънәсен үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1. | Инвалидлар өчен остазлар саны (аларның хезмәтенә түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен эш бирүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирелә) | кеше | 792 | | | | |

______________________________ ______________________________________________
(җитәкче вазыйфасы) (җитәкченең (индивидуаль эшмәкәрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

М.У.[1]

Баш бухгалтер ___________________ ____________________________________________
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

20__ел, «___» _______________

___________________

[1]Мөһер булганда.

___________________________________